Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559 ) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.10.2020 ел № 12

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы» муниципаль берәмлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 2018 елның 7 маендагы 91 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә,Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының шәһәр тибындагы Җәлил поселогы Советы 2018 елның 7 маендагы 91 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен әлеге карарның 1 пункты нигезендә, муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN.RU) һәм «Интернет»мәгълүмат -

телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстеннән калдырам

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе Р. Ә. Кәримов